| | | |
|---|---|---|
| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

23.01.2015 № 4-п

Саба муниципаль районы җирлекләре арасында
“Театр фестивале” оештыру турында

Саба муниципаль районы җирлекләрендә халыкның буш вакытын файдалы итеп оештыру, театр сәнгатен популярлаштыру һәм халыкны үзешчән сәнгатькә тарту максатыннан,

КАРАР БИРӘМ:

1. Район җирлекләрендә “Театр фестиваль” ләрен үткәрергә.
2. “Театр фестивале”н үткәрү буенча оештыру комиссиясен, графигын, нигезләмәсен һәм жюри составын расларга (1 нче, 2 нче, 3 нче, 4 нче кушымталар).
3. Графикта күрсәтелгән җирлекләрдә яшәүче талантлы хезмәткәрләрне барлап, аларның “Театр фестивален”дә катнашуын оештыруны авыл мәдәният йөртлары һәм авыл клублары мөдирләренә тәкъдим итәргә.
4. “Театр фестивале”нә репертуар сайлауны район үзәк һәм авыл китапханәләренә тәкъдим итәргә.
5. “Саба таңнары” газетасы редакциясенә, “Саба дулкыннары” теле-радиокомпаниясенә “Театр фестиваль”ләренең барышын даими яктыртып баруны тәкъдим итәргә.
6. Спектакльләрнең әзерлеген һәм авылларга чыгу өчен техника белән тәэмин итүне авыл җирлеге башлыкларына тәкъдим итәргә.
7. Аеруча яхшы дип табылган театр коллективларын бүләкләү өчен акча чыгымнарын табуны район Финанс–бюджет палатасына тәкъдим итәргә.

Р.Н.Минниханов

1 кушымта
Саба муниципаль районы башлыгының
"23" январь 2015ел
4-п карары белән расланды

Саба муниципаль районы җирлекләре арасында
"Театр фестивале" үткәрү буенча оештыру комиссиясе

| | |
|---|---|
| Шәрәфиев Т.Г. | - Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасары |
| Хафизов М.Г. | - Саба муниципаль районы Башкарма комитеты мәдәният бүлеге начальнигы |
| Исмәгыйлов Р.Р. | - "Саба таңнары" газетасы редакторы |
| Мөбәрәкова Ә.Г. | - "Саба дулкыннары" телерадиокомпаниясе директоры |
| Кәримов М.Р. | - Район мәдәният йорты өлкән методисты |
| Зиннуров А.М. | - "Саба үзәкләштерелгән авыл клуб системасы" (Район мәдәният йорты) муниципаль бюджет учреждениесе директоры |
| Габделхаков А.Г. | - "Саба үзәкләштерелгән авыл клуб системасы" (Район мәдәният йорты) муниципаль бюджет учреждениесе директоры урынбасары |

2 кушымта
Саба муниципаль районы башлыгының
“ 23 ” январь 2015ел
4-п карары белән расланды

Саба муниципаль районы җирлекләре арасында
“Театр фестивале”н үткәрү графигы

| № | Спектакль куючы җирлек | Үткәрү көне | Үткәрү урыны |
|---|---|---|---|
| 1. | Эзмә авыл җирлеге | 14.02.2015 | Тимершык мәдәният йорты |
| | Тимершык авыл җирлеге | 15.02.2015 | Эзмә мәдәният йорты |
| 2. | Түбән Шытсу авыл җирлеге | 21.02.2015 | Сатыш мәдәният йорты |
| | Сатыш авыл җирлеге | 22.02.2015 | Түбән Шытсу мәдәният йорты |
| 3. | Олы Нырты авыл җирлеге | 28.02.2015 | Юлбат мәдәният йорты |
| | Юлбат авыл җирлеге | 01.03. 2015 | Олы Нырты мәдәният йорты |
| 4. | Мичән авыл җирлеге | 07.03.2015 | Кече Шыңар мәдәният йорты |
| | Олы Шыңар авыл җирлеге | 08.03.2015 | Иске Мичән мәдәният йорты |
| 5. | Килдебәк авыл җирлеге | 14.03.2015 | Ике Басу Арташ мәдәният йорты |
| | Арташ авыл җирлеге | 15.03.2015 | Килдебәк мәдәният йорты |
| 6. | Явлаштау авыл җирлеге | 21.03.2015 | Шекше мәдәният йорты |
| | Шекше авыл җирлеге | 22.03.2015 | Явлаштау мәдәният йорты |
| 7. | Югары Симет авыл җирлеге | 28.03.2015 | Курсабаш мәдәният йорты |
| | Курсабаш авыл җирлеге | 29.03.2015 | Югары Симет мәдәният йорты |
| 8. | Лесхоз авыл җирлеге | 04.04.2015 | Иштуган мәдәният йорты |
| | Иштуган авыл җирлеге | 05.04.2015 | Лесхоз мәдәният йорты |
| 9. | Иске Икшермә авыл җирлеге | 11.04.2015 | Олы Кибәче авыл клубы |
| | Олы Кибәче авыл җирлеге | 12.04.2015 | Иске Икшермә мәдәният йорты |
| 10. | Шәмәрдән авыл җирлеге | 18.04.2015 | Саба мәдәният йорты |
| | Саба шәһәр җирлеге | 19.04.2015 | Шәмәрдән мәдәният йорты |

3 кушымта
Саба муниципаль районы башлыгының
“ 23 ” гыйнвар 2015ел
4-п карары белән расланды

Саба муниципаль районы җирлекләре арасында
“Театр фестивале” үткәрү

НИГЕЗЛӘМӘСЕ

1. “Театр фестивале” 2015 елның февраль, март, апрель айларында үз җирлекләренә кергән учреждениеләр катнашында авыл клубларында, мәдәният йортларында үтә.
2. Спектакльләрне бәяләү өчен жюри составы мәдәният белгечләре катнашында төзелә. “Театр фестивале” бәйге рәвешендә үткәрелә.
3. Чыгыш ясау вакыты һәр коллектив өчен бер сәгать ярым, яисә ике сәгать бирелә. Яхшы дип тапкан спектакльләр 5 (биш) баллы система белән бәяләнә.
4. Уңышлы дип саналган спектакльләр Байлар Сабасы һәм Шәмәрдәндә булачак фестивальнең йомгаклау кичәсенә чакырыла.
5. Авыл җирлекләренә кергән һәр авыл клубы, мәдәният йортлары аерым спектакль белән чыгыш ясап, иң яхшы дигән коллектив театр фестиваленә тәкъдим ителә.

4 кушымта
Саба муниципаль районы башлыгының
“ 23 ” гыйнвар 2015ел
4-п карары белән расланды

Саба муниципаль районы җирлекләре арасында
“Театр фестивале” үткәрү буенча жюри составы

| | |
|---|---|
| Зиннуров А.М. | - “Саба үзәкләштерелгән авыл клуб системасы” (Район мәдәният йорты) муниципаль бюджет учреждениесе директоры |
| Габделхаков А.Г. | - “Саба үзәкләштерелгән авыл клуб системасы” (Район мәдәният йорты) муниципаль бюджет учреждениесе директоры урынбасары |
| Кәримов М.Р. | - Район мәдәният йортының өлкән методисты |
| Габделхакова М.Т. | - Район мәдәният йортының “Ләйсән” үзешчән сәнгать бригадасы режиссеры |
| Габделхаков Г.Г. | - Район мәдәният йортының үзешчән сәнгать җитәкчесе |
| Тимербаева З.З. | - Район мәдәният йортының үзешчән сәнгать буенча методист |
| Тимербаев Х.Р. | - “Саба чишмәләре” клуб берләшмәсе җитәкчесе |
| Зарипова Ф.М. | - Район мәдәният йортының клуб эшләре методикасы буенча белгеч |
| Нурмөхәммәтова Г.В. | -“Саба үзәкләштерелгән авыл клуб системасы” (Район мәдәният йорты) муниципаль бюджет учреждениесенең 57 нче номерлы филиал мөдире (Күчмә клуб) |
| Нурисламова Э.И. | - “Саба үзәкләштерелгән авыл клуб системасы” (Район мәдәният йорты) муниципаль бюджет учреждениесенең 56 нчы номерлы филиал мөдире (Күчмә клуб) |
| Мансурова Л.Ф. | - “Саба үзәкләштерелгән авыл клуб системасы” (Район мәдәният йорты) муниципаль бюджет учреждениесенең 58 нче номерлы филиал мөдире (Күчмә клуб) |
| Гыймадиев Б.Р. | - Район мәдәният йортының “Биләр” халык ансамбле җитәкчесе |